| | | |
|---|---|---|
| **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАР СУЫКСУЫ АВЫЛ СОВЕТЫ**<br><br>423736, Татар Суксуы авылы, Гагарин урамы 1 б нче йорт. Тел. 3-44-60 | | **СОВЕТ ТАТАРСКО-СУКСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**<br><br>423736, село Татарские Суксы, Ул. Гагарина, дом 1 б. Тел. 3-44-60 |

**КАРАР**

**№ 21** **03.07.2019**

**Актаныш муниципаль районы Татар Суксуы авыл җирлеге Советының 2013 елының 1 гыйнварендагы санлы "Халык тыңлауларын оештыру турында Нигезләмәне раслау хакында" карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, " Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2017 елның 29 декабрендәге 455-ФЗ номерлы Федераль закон, " Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә турында», Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Татар Суксуы авыл җирлеге Уставы, Татар Суксуы авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Актаныш муниципаль районы Татар Суксуы авыл җирлеге Советының 2013 елдан _ _ _санлы "Халык тыңлауларын оештыру турында Нигезләмәне раслау хакында" карарының 3 статьясындагы 2 пунктының 4 пунктчасына үзгәрешләр кертергә һәм киләсе редакциядә бәян итәргә:

"4) генераль планнар проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне межалау проектлары, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары, күрсәтелгән расланган документларның берсенә, җир кишәрлеген яки капиталь төзелеш объектын шартлы рөхсәт ителгән файдалануга рөхсәт бирү турында карар проектлары, рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан кире кагуга рөхсәт бирү турында карар проектлары, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәт бирү турында карар проектлары буенча; җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән башка төр файдалану мәсьәләләре буенча җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең расланган кагыйдәләре булмаганда иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар үткәрелә, аларны оештыру һәм үткәрү тәртибе шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезләмәләрен исәпкә алып муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы Уставы һәм (яисә) норматив хокукый акты белән билгеләнә;».

2.Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татар Суксуы авыл җирлеге сайтында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерү

3.Карар үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татар Суксуы авыл җирлеге
Советы рәисе Р.Г.Харисов